КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 6 март г.Казань № 139

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының аерым дәүләт казна учреждениеләрен кушу юлы белән үзгәртеп оештыру турында» 2017 ел, 1 март, 124 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының аерым дәүләт казна учреждениеләрен кушу юлы белән үзгәртеп оештыру турында» 2017 ел, 1 март, 124 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктта:

өченче абзацта «213,0» саннарын «228,0» саннарына алыштырырга;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Республика ресурс үзәге» дәүләт казна учреждениесе эшчәнлегенең төп максатлары – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән күздә тотылган түбәндәге вәкаләтләрен тормышка ашыруны тәэмин итү максатларында, дәүләт хезмәтләре күрсәтү, эшләр башкару һәм (яки) дәүләт функцияләрен үтәү:»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«халыкка психологик ярдәм күрсәтүнең комплексслы системасын тормышка ашыру, Татарстан Республикасында халыкка психологик ярдәм күрсәтүче дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр һәм оешмалар эшчәнлеген мониторинглау, югарыда күрсәтеп үтелгән учреждениеләр белгечләре эшчәнлегенә методик һәм консультация ярдәме күрсәтү, шул исәптән халыкка психологик ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча норматив хокук актлары проектын эшләү турында тәкъдимнәр әзерләү, норматив хокук актлары мәгълүматларының мәгълүмати-белешмә базасын

формалаштыруда һәм актуаль хәлдә тотуда катнашу, психологик хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә һөнәри эшчәнлекне гамәлгә ашыру буенча методик һәм мәгълүмати-аналитик материаллар әзерләү, учреждениеләр эшчәнлеге тәҗрибәсенә эшнең нәтиҗәле формаларын һәм ысулларын кертү, җәмгыятьтә психологик киеренкелекне анализлау һәм мониторинглау, белгечләр эшчәнлегенә консультация ярдәме күрсәтү һәм аны мәгълүмати тәэмин итү, халыкка психологик ярдәм күрсәтүче белгечләр һәм учреждениеләр эшчәнлегенең статистика хисаплылыгы һәм исәбе системасын камилләштерүдә һәм үстерүдә катнашу, Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы ведомствосы буйсынуындагы учреждениеләрдә психологик хезмәтләр күрсәтүче белгечләрнең һөнәри компетенцияләрен (белгечләрне тәҗрибә алу юнәлешендәге өзлексез әзерләү системасын үстерү максатларында, конференцияләр, «түгәрәк өстәлләр» утырышлары, семинарлар һәм тәҗрибә алмашуның башка формаларын оештыруны һәм үткәрүне дә кертеп) арттыру;

тармак хезмәткәрләренең һөнәри компетенцияләрен арттыру, шул исәптән һөнәри әзерләү, яңадан әзерләү, квалификация күтәрү һәм стажировка үтү (белем бирү барышын фәнни-методик яктан тәэмин итү һәм булышлык күрсәтүне дә кертеп);

гражданның социаль хезмәт күрсәтүдә мохтаҗлыгын һәм социаль хезмәтләргә индивидуаль ихтыяҗын билгеләү, социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү, социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр реестрын һәм социаль хезмәтләрдән файдаланучылар регистрын формалаштыру һәм алып бару;

«Татарстан Республикасында социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булманнар һәм гаиләләр исәбе һәм мониторингы» мәгълүмати ярдәмче системасын функциональ администраторлаштыру, «Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасының «Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүне оештыру» мәгълүмати ярдәмче системасы алып барылышын тәэмин итү;

тармак белгечләре өчен мәгълүмати-методик база булдыру;

гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү тармагында инновацияле, тәҗрибә-эксперимент, грант эшчәнлеген оештыру;

тармак белгечләре өчен супервизияләр, методик, тәҗрибә алу юнәлешендәге семинарлар һәм конференцияләр оештыру һәм үткәрү;

социаль хезмәт күрсәтү оешмалары базасында ирекледәр отрядлары эшчәнлеген үстерү һәм яраштыру;

архив документларын саклау, оешмалар һәм ведомстволар, шулай ук гражданнар сораулары буенча 2016 елның 1 гыйнварына кадәр инвалидларны һәм ветераннар арасыннан гражданнарның аерым категорияләрен социаль яклау буенча күрсәтелгән чаралар турында, медицина күрсәткечләре булганда шифаханә-курорт дәвалавына юлламалар бирү, дәвалану урынына кадәр һәм кире кайту өчен шәһәрара транспортта түләүсез юл йөрү өлешендә дәүләт социаль хезмәт күрсәтү турында мәгълүмат бирү.».

2. Бу карарның гамәле 2018 елның 15 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин